

«Атюрьево 2 нче урта мәктәбе» ндә чын бәйрәм рухы хокем сорде – биредә Россия халыклары бердәмлеге елына багышланган Гаилә ижаты фестивале узды. Бу вакыйга торле милләт гаиләләре очен vз мәдәниятләренен байлыгын кvрсәтv, дуслык һәм vзара анлашу бәйләнешләрен ныгыту очен менә дигән момкинлек булган.      Россиянен коче - анын кvп-торлелегендә һәм халыклар бер-дәмлегендә. Шулай, чарада рус, мукшы, татар милләтле гаиләләр катнашып vз гаиләләрендә ата-бабаларыннан килгән гаилә ижаты, мәдәнияты турында сойләделәр, милли ашлардан авыз иттеләр. Татар гаиләләрен Наилә Амир кызы Ингильдеева кызы Камила белән; Иртуганова Амелия әнисе Изольда Булат кызы һәм әбисе Алимә Загидулла кызы; Эльвира Хәйдар кызы Совешова (мәктәп завучы) кардәше Рамиль белән тәгъдим иттеләр. Мәктәп залы ачык тосләр һәм хуш исләр белән тулган иде. Шул матурлыкта гаиләләр милли киемнәрен горурланып тәкъдим иттеләр: аларнын һәрберсе халыкнын vзенчәлеген һәм тарихын чагылдырган чын сәнгать әсәре иде. Иртуганова




Амелия татар хатын-кызларынын милли киемнәре турында сойләде, бигрәк калфак белән камзулга туктады. Ингильдеевалар татар милли гореф-гадәтләребез, милли мәдәниятыбыз турында сойләгәндә гаиләләре кvпмилләтле икәнен әйтеп киттеләр. Алар бер-берләренен мәдәниятын баетып, бергә-бергә дус-тату яшиләр. Шул вакыт без тагы да кочле.

Фестиваль остәлләре яраткан һәм борынгы рецептлар буенча әзерләнгән традицион ризыклар белән дә тулган иде. Хуш исле сыйлар бәйрәмгә тәмле остәмә генә тvгел, ә жылы әнгәмәләр һәм кулинария серләре белән уртаклашу очен сәбәп тә булды. Амелиянен әбисе Алимә Загидулла кызы белән әнисе Изольда Булат кызы пешергән милли ризыкларыбыз фестиваль остәлләренен бизәге булды, ә Эльвира Хәйдар кызы пешергән пә-рәмәчләр белән кош телен барысы да яратып ашады.



Программада халык традицияләре турындагы хикәяләр аерым урын алды. Гаиләләр рус,

мукшы, татар ата-бабаларынын бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре, һонәрләре һәм фольклоры турындагы тарихлары белән бик тә теләп уртаклаштылар. Бу илебездә яшәvче мәдәниятләрнен кvпкыр-лы доньясына чуму иде. Руслар, мукшылар белән бергә, Хәйдар кызы Эльвира да татар милли мәдәниятыбыз, якташ язучыларыбыз Фәхрел-Ислам Агеев, Һади Такташ, Абдурахман Абсалямов турында кызыклы ит тереп фестивальдә катнашучыларга сойләде. Укучылар олкәннәрнен сойләгәннәрен кызыксынып тынладылар, сораулар бирделәр һәм интерактив элементлар - халык биюләрен ойрәнv, милли уеннар белән танышуда рәхәтләнеп катнаштылар.
Атюрьево мәктәбендә vткән Гаилә иҗаты фестивале гади чара гына тvгел, ә мәдәни мирасны буыннан-буынга саклау һәм тапшыру моһимлегенен якты vрнәге булды. Ул Россия халыкларынын бердәмлеге – сvзләр генә тvгел, ә бер-берсенен гореф-гадәтләрен хормәт итvдә, vз тәҗрибән белән уртаклашырга әзерлектә һәм кvршеләр турында кvбрәк белергә теләvдә чагыла торган чынбарлык булуын кvрсәтте. Мондый вакыйгалар гаилә кыйммәтләрен ныгыта һәм һәркем vзен зур һәм тату гаилә олеше итеп хис итә торган гармонияле җәмгыять формалаштыруга ярдәм итә.

**Наилә НАСЫРОВА**